инвестиция программасы чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнарның нигезле булуын тикшерә;

кулланучылар өчен оешма тарифларының файдалана алырлык булуы яисә файдалана алырлык булмавы турында Дәүләт комитеты бәяләмәсен исәпкә алып, көйләнә торган яки көйләнми торган оешма тарифларының кулланучылар өчен файдалана алырлык булуын тикшерә;

инвестиция программасында Министрлык һәм региональ оператор арасындагы килешүдә, концессия килешүендә, дәүләт-шәхси партнерлык, муниципаль-шәхси партнерлык турындагы килешүдә, инвестиция шартнамәсендә каралмаган чараларның, шулай ук инвестиция программасы чараларын гамәлгә ашыру параметрларының булуын тикшерә;

Инвестиция программасы чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнарның нигезлелеген тикшерү максатларында Министрлык экспертларны җәлеп итәргә, шундый чараларны гамәлгә ашыруга чыгымнар белән чагыштырулар уздырырга, инвестиция программасы чараларын гамәлгә ашырганда сатып алына торган товарларга, эшләргә һәм хезмәтләргә котировкалар соратырга хокуклы.

Инвестиция программасы чараларын гамәлгә ашыруга чыгымнарның нигезлелеген тикшергәндә, искәрмәләр булган очракта, Министрлык көйләнә торган яки көйләнми торган оешмадан нигезләүче исәпләмәләрне таләп итәргә хокуклы.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар инвестиция программалары бүлегенә һәм калдыклар белән эш итү бүлегенә кергән көннән алып 14 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырылган документларга карата кисәтүләр булуы яисә булмавы.

3.7. Инвестиция программасын раслау турында карар кабул итү яисә инвестиция программасын раслаудан баш тарту турында карар кабул итү

3.7.1. Тапшырылган документларга карата кисәтүләр булган очракта, аларны карау нәтиҗәләре буенча калдыклар белән эш итү бүлегенең вазыйфаи заты, шул исәптән регламентның 3.4 пунктында билгеләнгән, компетенция чикләрендә бүлекләрнең вазыйфаи затлары тарафыннан әзерләнгән кисәтүләр нигезендә баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, инвестиция программасын раслаудан баш тарту турындагы карар белән мөрәҗәгать итүче адресына язма белдерү проектын әзерли. Инвестиция программасын раслаудан баш тарту турында карар белән мөрәҗәгать итүче адресына язма белдерү проекты калдыклар белән эш итү бүлеге җитәкчесе, инвестиция программалары бүлеге җитәкчесе, торак-коммуналь хуҗалык идарәсе җитәкчесе, министр урынбасары белән килештерелә.

Министрлыкта алына торган корреспонденцияне теркәү өчен җаваплы булган Министрлыкның документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенең вазыйфаи заты аны терки.

Министрлыкның документлар үтәлешен тикшерүдә тоту бүлегенең Министрлыкка килгән корреспонденцияне теркәү өчен җаваплы вазыйфаи заты,

